КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1446

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәт-кәрләренә махсус социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 3 апрель, 395 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 03 апрель, 395 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) территориаль участок принцибы буенча беркетелгән халыкка беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче, шулай ук гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында эшләүче, авыруына (хәленә) бәйле рәвештә һәм профилактика максаты (тикшерүләр үткәрүне кертеп) белән гражданнар мөрәҗәгать итүче (булучы) табибларга һәм югары белемле (медицина булмаган) медицина хезмәткәрләренә– 14 500,0 сум;

үзәк район, район һәм участок хастаханәләренең югары белемле медицина хезмәткәрләренә, әлеге пунктчаның беренче абзацында һәм «б» пунктчасында күрсәтелгән медицина хезмәткәрләреннән тыш, – 18 500,0 сум;»;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) табибларга һәм өлкәннәргә күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең югары белемле (медицина булмаган) медицина хезмәткәрләренә - 11 500,0 сум;

өлкәннәргә күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең урта медицина белеме булган белгечләргә - 7 000,0 сум.».

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин